Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Иске Кади авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гражданнары җыены карары

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Иске Кади авыл җирлеге составына керүче
Иске Кади, Тукай, Светлогорский, Якты Тау
торак пунктларында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

13.10.2021 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә киләсе мәсьәлә буенча 12.10.-13.10.2021 ел булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән йомгаклау беркетмәсе төзелде «2022 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы?, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән:

- Иске Кади, Якты Тау, Тукай, Светлогорский торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары.
- Иске Кади авыл җирлеге территориясендә язгы ташудан соң сулыкка янгынга каршы юлларны торгызу

- Иске Кади торак пунктында Телевизор урамындагы 150 метр, Якты Тау торак пунктында Дальняя урамында 150 метр урам-юл челтәрен төзекләндерү (20-30 мм фракциядәге вак таш сатып алу) югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Иске Кади, Якты Тау, Тукай һәм Светлогорский торак пунктларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын вакытында хәбәр итү системасын сатып алу һәм урнаштыру, сулыкларның һәм янгын гидрантларының күрсәткечләрен сатып алу һәм урнаштыру, янгыннарны сүндерү өчен кирәкле җиһазлар сатып алу,

янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру, ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

- каты коммуналь калдыкларның вакытлыча җыелу урыннарын төзекләндерү буенча проект-смета документларын әзерләү, каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм оештыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- иҗтимагый киңлекләрне төзекләндерү, Иске Кади, Якты Тау, Тукай торак пунктларында авыл территорияләрен үстерү буенча дәүләт программаларында катнашу өчен проект-смета документациясен әзерләү һәм түләү чыгымнары

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 603 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 603 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 328 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1.Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге составына керүче Иске Кади, Тукай, Светлогорский, Якты Тау торак пунктларында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2022 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы?, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән:

- Иске Кади, Якты Тау, Тукай, Светлогорский торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары.

- Иске Кади авыл җирлеге территориясендә язгы ташудан соң сулыкка янгынга каршы юлларны торгызу

- Иске Кади торак пунктында Телевизор урамындагы 150 метр, Якты Тау торак пунктында Дальняя урамында 150 метр урам-юл челтәрен төзекләндерү (20-30 мм фракциядәге вак таш сатып алу) югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Иске Кади, Якты Тау, Тукай һәм Светлогорский торак пунктларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын вакытында хәбәр итү системасын сатып алу һәм урнаштыру, сулыкларның һәм янгын гидрантларының күрсәткечләрен сатып алу һәм урнаштыру, янгыннарны сүндерү өчен кирәкле җиһазлар сатып алу, янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру, ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

- каты коммуналь калдыкларның вакытлыча җыелу урыннарын төзекләндерү буенча проект-смета документларын әзерләү, каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм оештыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- иҗтимагый киңлекләрне төзекләндерү, Иске Кади, Якты Тау, Тукай торак пунктларында авыл территорияләрен үстерү буенча дәүләт программалары буенча катнашу өчен проект-смета документациясен әзерләү һәм түләү чыгымнары

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: Иске Кади авылы, Совет ур., 6нчы йорт, Чирмешән муниципаль районының рәсми интернет-сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлеге башлыгы Н.В.Мөктәсимов